**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Кече Салтык авыл җирлеге Советы КАРАРЫ**

**2017 елның «30» гыйнвары №46**

**;**

**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Кече Салтык авыл җирлеге Советының «2016 елга Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Кече Салтык авыл җирлеге бюджеты турында» 2015 елның 19 декабрендәге 15 номерлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында**

( 2016елның 10 августындагы 30 номерлы редакциядә № 41, 18.11.2016г.

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының кече Салтык авыл җирлегенең 81 статьясы һәм Кама Тамагы муниципаль районы Советының 2013 елның 18 декабрендәге 201 номерлы карары белән расланган Кама Тамагы муниципаль районында бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турындагы нигезләмә нигезендә Кама Тамагы муниципаль районының Кече Салтык авыл җирлеге Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. “2016 елга Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Кече Салтык авыл җирлеге бюджеты турында” 2015 елның 19 декабрендәге 15 номерлы Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Кече Салтык авыл җирлеге Советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне исәпкә алып кертергә:

1. 1 статьяда;

а) 1.1 пунктта «3001,6» саннарын «3513,5» саннарына алмаштырырга

б) 1.2 пунктта ««3001,6» саннарын «3616,8» саннарына алмаштырырга

в) 1.3 пунктта «0» санын «103,3» санына алмаштырырга

1.2. Карарны түбәндәге эчтәлекле 10.3,10.4 статьялары белән тулыландырырга:

«10.3 Татарстан Республикасы Кама Тамагы районының Кече Салтык авыл җирлеге бюджетында җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә муниципаль берәмлекләр бюджетларына тапшырыла торган, 2016 елда гражданнарның үзара салым акчаларын җәлеп итеп, 330,8 мең сум күләмендә гамәлгә ашырыла торган бюджетара трансфертларны расларга.»

«10.4 Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Кече Салтык авыл җирлеге бюджетында башка дәрәҗәдәге хакимият органнары тарафыннан 2016 елда 823,3 мең сум күләмендә кабул ителгән карарлар нәтиҗәсендә барлыкка килгән компенсация, өстәмә чыгымнар өчен тапшырыла торган бюджетара трансфертларны расларга.»

2. Әлеге карар түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат такталарында рәсми басылып чыккан (халыкка җиткерелгән) көннән үз көченә керә:

- Татарстан Республикасы, Кама Тамагы районы, Кече Салтык авылы, Бакый Урманче ур., 9, Мәдәният йорты бинасы;

- ТР, Кама Тамагы районы, Кече Мәрәтхуҗа авылы, Вахитов ур., 9 йорт, авыл китапханәсе мәдәният йорты бинасына;
- Татарстан Республикасы, Кама Тамагы районы, Яшелчә авылы, Идел ур., 4а йорт, авыл клубы бинасы һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында.

3. 1-5 нче кушымталар редакциясендәге карарга 1, 2, 6, 7, 8 нче кушымталарны чыгарырга.

**Кече Салтык авыл җирлеге башлыгы Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Кече Салтык авыл җирлеге советы рәисе Җиһаншин А.Г.**